Чыганак: **Сөембикә.- 2007.- № 5.- Б. 48-49**



*"Бакый" исеменең ни икәнен*
*Белеп йөрсәм дә мин әлек,*
*Әле генә тойдым чын мәгънәсен,*
*Чын сәнгать ул — Бакый — Мәңгелек.*

Илдар ЮЗЕЕВ.

# Милләт әһеле

## Бакый Урманченың тууына 110 ел тулу уңаеннан

Бакый Идрис улы Урманче — татар мәдәниятенең күренекле осталарыннан берсе. Татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучылардан буларак, аның самими, тирән үзенчәлекле иҗаты, сәнгать чараларының байлыгы зур тәэсир көченә ия булган сәнгать әсәрләрен тудыруга сәбәп булды, татар халкының үзаңына — аның рухи дөньясының какшамас бер өлешенә әверелде. Урманче иҗатының киң кодрәте стан һәм дивар нәкыше, скульптура, милли корымчылык өлкәсен, кул һөнәре, театр бизәү, рәсем, гравюра, китап бизәү сәнгатьләрен үз эченә алды. Оста иҗатының һәм шәхесенең татар сынлы сәнгать үсеше өлкәсендәге әһәмияте С. Сәйдәшев һәм С. Садыйкованың — татар музыкасын, Г. Тукай һәм М. Җәлилнең — әдәбиятны, Г. Кариев белән Г. Камалның татар театрын үстерүдәге роленә тиң. Урманче иҗатының даими эзләнүләре сәнгатьтә милли теманың гәүдәләнүендә чагылды.

Рәссамның "вакыт һәм үзе" турындагы уйланулары, анын бәһасен җуймас рухи кыйммәтләре — гүзәллек эзләү омтылышлары халыкның тормыш фәлсәфәсе һәм эстетик идеалы белән бергә кушыла. Шунлыктан Бакый Урманче иҗаты һәр кешегә якын һәм аңлаешлы.

## Замандашлары Бакый Урманче турында

Мин останың дүрт компонентка нигезләнгән иҗади куәтен бәялләп китәр идем. Беренчедән, бу, әлбәттә, идея — әсәр зур илаһи идея, тирән фикер исәбенә җанландырыла, дөньяга туа. Бу — патриотизм, ватанпәрвәрлек, туган халкыңа, хезмәт-иҗат кешесенә карата мәхәббәт, туган табигатең белән соклану, аның гүзәллеге идеясе булырга мөмкин. Икенчедән, бу әсәрне тоташ биләп торган тирән хисләр өермәсе. Автор битараф түгел, аның бу дулкынлануы безгә дә күчә. Үзеңнең хис-халәтеңне тамашачыга өрү, күчерү, тойдырырлык итеп сурәтли, тапшыра белү сәләте — талантның масштаблыгы һәм тирәнлеге күрсәткече. Өченчедән, Бакый Урманче — гаҗәеп колорист. Җитен тукыма өстендәге буяулар саф һәм янып сулкылдыйлар, алар җанлы, бер-бере белән тоташуы табигый һәм тетрәндергеч матур, һәм безнең күзләребез нәкышне дулкынланып караудан аерыла алмыйлар.

Һәм, ниһаять, иң мөһиме. Оста — бу сүзнең, чын мәгънәсендә, милли... Милли хис безнең күңелләребездәге иң тирән хисләрнең берсе. Рәссам безнең халкыбызның күркәмлеген һәм гүзәллеген күрсәтә. Ул бездә үз-үзебезгә карата ихтирам һәм горурлык хисен уята, киләчәккә карата оптимизм һәм ышану тойгыларын тудыра.

**Камил ВӘЛИЕВ.**
**"Оста хакында сүз".**

Урманче иҗатының көчле бер сыйфаты — ул тудырган образларның тирән психологик көче. Рәссам тарафыннан башкарылган портретлар галереясе — гаҗәп самимилеге вә куәте белән күзгә ташлана. Портрет иҗат итәргә алынганда рәссам — кеше шәхесендәге төп сыйфатларны, аның рухи тормышын, иҗади башлангычын бер сурәт кысаларында тулы бер биография итеп бирергә омтыла. Әхлакый кыйммәтләр турында, кешенең чикләнмәгән мөмкинчелекләре турындагы уйланулары, шәхеснең эчке дөньясына керү, киң гамма хисләр кат-

нашмасын сурәтләп бирү осталыгы — тайпылгысыз рәвештә бөтен әсәрләрен нәкъ аңа хас булганча җанландырып бирәләр.

Сәнгатьтә үзенчә — индивидуаль рәвештә — фикер йөртү хакын Урманче лаеклы рәвештә дистәләгән ел хезмәт нәтиҗәсендә, тормышны тирәннән өйрәнеп эш итү нәтиҗәсе буларак яулап ала. Ул үз заманының асылын зур итеп тотып ала белә һәм аңа тиешле яңгыраш бирә. Аның әсәрләренең күтәренке яңгырашы заман модасына бирелү яки соцреализм идеологиясенең “шапырынуы” түгел. Бу рәссамның тирән инануларының чагылышы, аның сәнгатенең философиясе һәм дөньяны күзаллавының шәкеле. Кеше — бәхет, иҗат рәхәтлеге, шатлык китерә торган иркле хезмәт өчен туган, ди Урманче үзенең һәрбер әсәре белән. Ул үзенең акылы һәм куллары тудырган гүзәл хезмәт җимеше исәбенә бөек. Кеше идеалын оста тормышның үзәгендә эзли. Аның әсәрләре натурага яратып карау, чынбарлыкның үзеннән чыккан, гүзәл итеп сынландырылган гармония һәм матурлык белән күңелләрне җәлеп итә.

**Анатолий НОВИЦКИЙ.**
**“Юл ачучы”.**

Хәтерлим: остаханәгә килеп керүем булды... мондагы шәхесләрнең катгый, чәнечкеле карашларын тойдым. Бу ниндидер югары форумны хәтерләткән сыман иде... Тантаналы җыелышның түрендә XIII гасырның каһарман шагыйре Кол Гали утыра. Аның белән янәшә философ-галим, энциклопедист, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани һәм аның замандашлары балкып утыралар. Аннан — халыкның әдәби, мәдәни тормышында кабатланмас роль уйнаган Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Дәрдмәнд, Х. Ямашев, М. Вахитовлар. Әсәрдә бу мәҗлесне җыйган зат ниндидер сәбәпләр буенча халыкның ниндидер танылган улын, әйтик, С. Сәйдәш яисә М. Җәлилне онытып калдырган булса, бу форум, чын мәгънәсендә, тулы хокуклы булмас иде. Менә бу гасырлар буена чарланган милләт әһелләре, акыллы ирләр бергә җыелып, философик акыл һәм сабырлык белән халыкның киләчәге, бүгенгесе турында сөйләшеп, гәпләшеп утыралар... Бу талантларның гаҗәп күплеге, иҗатлары һәм хезмәтләре белән үз халыкларына һәм башка халыкларга — үзләренең чын мөмкинчелекләрен күрсәтеп, аның кешелек алдында дәрәҗәсен күтәрүләре, чын мәгънәсендә, горурлык хисе уята. Бу — останың илһамлы сәләте исәбенә туып чыккан тарихи шәхесләрнең тезмәсендә — халыкның тарих юлларында үз башыннан кичергән драмалар һәм коллизияләре, аның тарафыннан кешелек мәдәнияте хәзинәсенә керткән тормыш нәтиҗәсе ярылып ята. Тукайның пәйгамбәрләрчә: татар халкының да үзенең бөек мирасы, ата-бабаларыннан калган илаһи сәнгать әсәрләре булуы турындагы сүзләре — физик тотрыклылык алган сыман була, йөрәкләрдә хаклы рәвештә үз буынының хезмәте өчен җаваплылык туа, һәм син бу дөньяда үзеңнең ватансыз, исемсез, традициясез, нәселсез дәрвиш түгел икәнеңне аңлыйсың һәм син тулы хокук белән бу бөек шәхесләр калдырган мирасны — тарихи һәм әдәби байлыкны кочып аласың. Ә бу җимешләрне алга таба яңа буынга алып бару — аларны үзләштерү һәм баету — синең бурычың, синең изге вазифаң.

**Гомәр БӘШИРОВ.**
**“Бәхетле иҗат”.**

Бөтен иҗат гомере буена, осталыгының төрле этапларында — йә күңелен алгысытып, кайчакта рухландырып, кайвакыт шөбһәләндереп, Урманчега алтын канатлы ат — Тулпар күренгәли... Әлеге образны романтик яшьлек канатларында сурәтләүдән һәм моның белән үзенең әйләнеп кайтмас яшьлеге белән турыдан-туры беркатлы ассоциацияләрдән баш тартып, ул аны бары тик сәнгатьнең биләмәс көчен буйсындырып, тормыш каршылыклары алдында югалып калмау ныклыгын үзләштергән, үз-үзен аямый хезмәт итүче артист-виртуозга хас гаҗәеп җиңеллеккә һәм зиһенлеккә ирешкән чорда гына иҗат итә... Иң элек очып баручы хыялый ак ат образы декоратив паннода, ә аннары дулкынландыргыч сурәт рәвешендә агачта пәйда була.

Урманченең кул астында халык хыялында туган, аның кичереш-газапларын, шатлык-назларын бергә җыйган әлеге образ тыелгысыз рәвештә, арыталуны белмичә, үзеңне аямый алга бару символына әверелә.

...“Тулпар” — аның даими халәте, яшәү темпы, ритмы, тылсым көче, хәтта иманы. Бу кайнап торучы, тынмас, яңаны тудырырга омтылучы иҗат — киләсе буын сәнгать осталарына тапшырыла торган бәһасез мирасның сихри бер кисәге.

**Розалина ШАҺИЕВА.**
**“Олуг дәрәҗәдәге сәнгать остасы”.**

*(Б. Урманченың тууына 110 ел тулу уңаеннан уздырылган күргәзмә каталогыннан).*